ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

12 июля 2016г.

№ 3538

Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм һәм социаль булышлык итү буенча өстәмә чаралар күрсәтүгә хокукын тормышка ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 нче карары, Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2017елның 1 гыйнварыннан өч һәм аннан күбрәк баласы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 нче карарындагы гамәлләргә туры килми торган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирүне билгеләргә.

2. Расларга:

1) өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү комиссиясенең эш регламентын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү комиссияләре составын, 3 нче, 4 нче, 5 нче кушымталарда каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә:

1) 2017 елга һәм 2018-2019 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирүгә чыгымнарны күздә тотарга;

2) өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирүгә бәйле чыгымнарны финанслауны 2017-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм муниципаль программасы кысаларында гамәлгә ашырырга;

3) 2017 ел дәвамында 2015 ел өчен өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирүгә бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

4. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен Башкарма комитетның Үзәк районы Хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Башкарма комитетның Автозавод районы Хакимияте Башлыгы Р.М. Усмановага, Комсомол районы Хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Н. Вафинга, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Управление делопроизводством / Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2016 елның 12 июлендәге
3538 нче карарына
1 нче кушымта

Оч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга
физик затлар милкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә
бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезнамә оч һәм аннан күбрәк баласы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының «Физик затлар милкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 нче карарындагы гамәлләргә туры килми торган гражданнарга физик затлар милкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве (алга таба – компенсация) билгеләү һәм бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Компенсация гариза бирүчегә, гариза бирүченең сайлавы буенча, гаиләгә туры килә торган бер торак фонд объекты (фатир (бүлмә) яки торак йорт) өчен физик затлар милкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә (пени һәм штрафлардан тыш) билгеләнә һәм түләнә.

3. Компенсация алуга хокук билгеләгәндә, компенсация өчен мөрәҗәгать иткән көнгә җан башына Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы зурлыгы күләмендәге уртача керем исәпкә алына.

Компенсация билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме, барлык кирәкле документлар белән бергә компенсация билгеләү турында гариза биргән айдан алдагы соңгы ел (алга таба – хисап елы) өчен билгеләнә.

Гаиләнең җан башына уртача керемен билгеләгәндә, аерым яки бергә яшәүләренә карамастан, гариза бирүченең ире (хатыны) булган гражданнарның керемнәре исәпкә алына.

Хисап чорында гаиләнең җан башына уртача кереме гаиләнең уртача айлык гомуми керемен гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнә.

4. Компенсация күләмен билгеләгәндә гаилә составында түбәндәгеләр исәпкә алына:

1) иждивениедә торучы һәм 18 яшькә җитмәгән балалар;

2) гаиләдә яшәүче үги малай һәм үги кыз, әгәр алар башка ата-ана гаиләсендә исәпләнмәсә;

3) гражданнар гаиләләрендә опекада торучы балалар;

4) тәрбиягә алган гаиләдә тәрбияләнүче балалар.

5. Ата-анасының (атасы яки анасы – тулы булмаган гаиләдә) икесе дә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки тулысынча дәүләт тәэминатында булган балалар гаилә составында исәпләнми.

## 2 бүлек. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

6. Гариза бирүче, компенсация алу өчен, яшәү урыны буенча Башкарма комитетның тиешле район Хакимиятенә түбәндәге документларны тапшыра:

1) әлеге нигезнамәнең кушымтасында каралган форма буенча гариза;

2) күп балалы гаилә таныклыгы;

3) гаилә бирүченең паспорт күчермәсе (2, 3, 5, 14, 16, 17 битләр);

4) башка ата яки ананың паспорт күчермәсе (2, 3, 5, 14, 16, 17 битләр);

5) балаларның туу турында таныклык күчермәсе, шулай ук ундүрт яшькә җиткән балаларның паспорт күчермәләре (2, 3, 5 битләр);

6) баланы улыкка (кызлыкка) алуны билгеләү турында суд карарының күчермәсе (баланың туу турында таныклыгында улыкка (кызлыкка) алучылар ата-ана буларак язылган очраклардан тыш);

7) опека һәм попечительлек органының опекун яки попечитель билгеләү турындагы акт күчермәсе (опека яки попечительлек билгеләнгән очракта);

8) опека яки попечительлекне гамәлгә ашыру турында килешү күчермәсе (опека яки попечительлекне килешү буенча гамәлгә ашырган очракта);

9) язылышу турында таныклык күчермәсе;

10) яшәү урыныннан белешмә;

11) компенсация бирү турында гариза биргән айдан алдагы соңгы ел өчен гаиләнең һәр әгъзасының керемнәре турында документлар;

12) физик затлар мөлкәтенә салым түләү турында квитанция күчермәсе;

13) физик затлар мөлкәтенә салым буенча белдерү кәгазенең күчермәсе;

14) гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслый торган документлар (ирекле формада):

- аларның персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы булу;

- Башкарма комитетның тиешле район Хакимиятенә персональ мәгълүматларны тапшырганда, гариза бирүченең алар исеменнән эш итү вәкаләтләре.

7. Әлеге нигезнамәнең 6 пунктында каралган документлар теркәлгән гариза бер эш көне эчендә өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү комиссиясенә (алга таба – комиссия) юллана.

Комиссия әлеге карар белән расланган эш регламентында каралган беркетмә формасында карар кабул итә.

8. Компенсация билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге нигезнамәнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тулысынча тапшырмау;

2) гамәлдә булу срогы чыккан документлар тапшыру (күрсәтү);

3) закон таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән документларны тапшыру.

9. Компенсация түләү Башкарма комитетның тиешле район Хакимияте тарафыннан Башкарма комитетның финанс идарәсенә агымдагы айның 30 числосына кадәр, раслаучы документларны теркәп, компенсация

түләүләрен финанслау өчен тапшырылган заявка һәм комиссия карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Компенсация суммасы гариза бирүченең банк счетына күчерелә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Оч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар милкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында нигезнамәгә кушымта

Башкарма комитетның
________________ районы

Хакимияте Башлыгына
________________________________
(ФИАсы, теркәлү буенча яшәү урыны,
________________________________
элемтә өчен телефон)

Оч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга
физик затлар милкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә
торган компенсация түләве бирү турында
гариза

Оч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар милкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирүне сорыйм.

Компенсация түләвен күчерү өчен реквизитлар:

________________________________________________________________
(банкның исеме, БИК, ИНН, счет №)

Кушымталар:

1) ________________________________________;
2) ________________________________________;
3) ________________________________________.

Гариза бирүче ________ ________

Дата ____________________

Башкарма комитетның
2016 елның 12 июлендәге
3538 нче карарына
2 нче кушымта

Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга
физик затлар милкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә
торган компенсация түләве бирү комиссиясенең
эш регламенты

1. Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар милкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү комиссиясе (алга таба – Комиссия) үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм һәм социаль булышлык итү буенча өстәмә чаралар күрсәтүгә хокукын тормышка ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 нче карарына, Шәһәр Советының «Физик затлар милкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 нче карарына һәм әлеге карарга таянып эш итә.

Комиссия, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү өчен, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарның гаризаларын карау максатында төзелә.

2. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.

3. Комиссиянең сан һәм персональ составы Башкарма комитет карары белән раслана.

4. Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) Комиссия рәисенә утырышны кичектерү турында тәкъдимнәр кертергә;

3) Комиссия утырышында катнашырга;

4) Комиссия тарафыннан карауга чыгарылгын мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга;

5) карауга чыгарылган мәсьәлә буенча фикерен белдерергә;

6) килешенү буенча, Комиссия эшенә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр вәкилләрен җәлеп итәргә.

5. Комиссия рәисе Комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) Комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

2) Комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны имзалый.

6. Комиссия рәисе урынбасары Комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын башкара.

7. Комиссия секретаре Комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) Комиссиянең эш кәгазьләрен алып бара;

2) Комиссия утырышларына материаллар әзерләүне, шулай ук беркетмә алып баруны оештыра;

3) чираттагы Комиссия утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында Комиссия әгъзаларына хәбәр итә, аларны белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

4) Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

5) Комиссия кабул иткән карар турындагы мәгълүматны гариза бирүче адресына җибәрә.

8. Комиссия утырышлары ай саен агымдагы айның 15 числосына кадәр үткәрелә. Составының өчтән ике өлеше катнашкан очракта, Комиссия утырышы тулы хокуклы санала. Комиссия әгъзалары утырышта шәхсән катнашалар. Комиссия әгъзасы утырышта булмаган очракта ул, карала торган мәсьәлә буенча үз фикерен язма рәвештә белдерү хокукына ия.

9. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм Комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан күбрәге тавыш биргән очракта, алар кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булган очракта утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала.

10. Комиссия карары әлеге регламент кушымтасында каралган формадагы беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм ул Комиссия утырышында рәислек итүче, рәис урынбасары, секретарь һәм Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү комиссиясенең эш регламентына кушымта

_______________________________________ комиссияse утырышының № ___ беркетмәсе

Яр Чаллы шәһәре «___»__________ 20__ .

Комиссия утырышында катнаштылар:
1. комиссия рәисе:

_____________________ - _____________________
Ф.И.А.и. вазыйфасының исеме

2. комиссия рәисе урынбасары:

_____________________ - _____________________
Ф.И.А.и. вазыйфасының исеме

3. комиссия секретаре:

_____________________ - _____________________
Ф.И.А.и. вазыйфасының исеме

4. комиссия әгъзалары:

_____________________ - _____________________
Ф.И.А.и. вазыйфасының исеме

_____________________ - _____________________
Ф.И.А.и. вазыйфасының исеме

Кворум бар.

Көн тәртибе:

_______________________________________ Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү мөмкинлеген карарга.

_______________________________________ нигезендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве алу мөмкинлеге турында

1) _______________________________________;
гариза җибәрүче затның исеме

гариза керде.

Тапшырылган документларны һәм материалларны карагannan соң, комиссия карар чыгарды:

_______________________________________________
затның исеме

бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирергә (бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирүне кире кагарга ______________________).
Тавыш бирделәр:
«ризга» - ; «каршы» - ; «тоткарланды» -

Комиссия рәисе: ______________________ ______________________
имза Ф.И.А.и.

Комиссия рәисе урынбасары ______________________ ______________________
имза Ф.И.А.и.

Комиссия секретаре: ______________________ ______________________
имза Ф.И.А.и.

Комиссия әгъзалары: ______________________ ______________________
имза Ф.И.А.и.

______________________ ______________________
имза Ф.И.А.и.

Башкарма комитетның
2016 елның 12 июлендәге
3538 нче карарына
3 нче кушымта

Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга
физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә
торган компенсация түләве бирү буенча шәһәр Башкарма комитеты
Комсомол районы Хакимиятенең комиссия
составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Вафин Р.Н. | - комиссия рәисе, Комсомол районы Хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 2. | Скибина Т.А. | - комиссия рәисе урынбасары, Комсомол районы Хакимияте Башлыгы урынбасары, халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы |
| 3. | Зәкиева Л.Р. | - комиссия секретаре, Комсомол районы Хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең баш белгече |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| 4 | Закирова Л.Ш. | - Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлегенең әйдәүче белгече |
| 5. | Майдуллина Э.Р. | - Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет бүлегенең баш белгече |
| 6. | Нургалиева Г.Ш. | - Комсомол районы Хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең баш белгече |
| 7. | Щелконогова Н.А. | - РФ Пенсия фондының ТР Яр Чаллы шәһәрендәге идарәсе (районара) ДУ пенсия түләү бүлеге башлыгы урынбасары (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2016 елның 12 июлендәге
3538 нче карарына
4 нче кушымта

Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга
физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә
торган компенсация түләве бирү буенча шәһәр Башкарма комитеты
Үзәк районы Хакимиятенең комиссия
составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Галимов И.Н. | - комиссия рәисе, Башкарма комитетның Үзәк районы Хакимияте Башлыгы |
| 2. | Кирилова В.А. | - комиссия рәисе урынбасары, Үзәк районы Хакимияте Башлыгы урынбасары, Үзәк районы Хакимиятенең мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге башлыгы |
| 3. | Гыйльметдинова Э.И. | - комиссия секретаре, Үзәк районы Хакимиятенең халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы |
| | Комиссия әгъзалары: | |
| 4. | Гарифуллина Л.Е. | - РФ Пенсия фондының ТР Яр Чаллы шәһәрендәге идарәсе (районара) ДУ пенсия билгеләү һәм яңадан исәпләү бүлеге башлыгы урынбасары (килешенү буенча) |
| 5. | Ермолаева Э.М. | - Үзәк районы Хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәүче белгече |
| 6. | Мтыгуллина А.М. | - Башкарма комитетның финанс идарәсе исәп һәм хисаплылык бүлегенең баш белгече |
| 7. | Сиражетдинов Р.И. | - Үзәк районы Хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең баш белгече |
| 8. | Ховрычева Н.В. | - Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлегенең әйдәүче белгече. |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Управление дело-производством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2016 елның 12 июлендәге
3538 нче карарына
5 нче кушымта

Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга
физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә
торган компенсация түләве бирү буенча шәһәр Башкарма комитеты
Автозавод районы Хакимиятенең комиссия
составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Усманова Р.М. | - комиссия рәисе, Башкарма комитетның Автозавод районы Хакимияте Башлыгы |
| 2. | Әлмөхәммәтова Е.Ю. | - комиссия рәисе урынбасары, Автозавод районы Хакимияте Башлыгы урынбасары, халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы |
| 3. | Сабирҗанова Г.Ф. | - комиссия секретаре, Автозавод районы Хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең баш белгече |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| 4. | Галиева Д.А. | - Автозавод районы Хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәүче белгече |
| 5. | Мурсякова С.В. | - Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлегенең әйдәүче белгече |
| 6. | Хәбибуллина Г.Ф. | - Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет бүлегенең баш белгече |
| 7. | Харисова Л.Р. | - Автозавод районы Хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәүче белгече |
| 8. | Шутенко А.Г. | - РФ Пенсия фондының ТР Яр Чаллы шәһәрендәге идарәсе (районара) ДУ социаль түләүләр бүлеге башлыгы (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова